**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
IV чакырылыш VII утырыш

2021 елның 15 сентябре № 70 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 июлендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 07 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм 2021 елның 7 сентябрендәге бәяләмә нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2014 елның 14 августындагы 37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шулай ук блоклы торак төзелеше өчен кулланыла торган җир участокларының минималь күләмнәре»нә түбәндәге эчтәлектәге **4.1 статья өстәргә:**

«1. Җир участокларының минималь күләмнәре:

1.1. Торак пунктлар чикләрендә индивидуаль торак төзелеше өчен - 1 000 кв.м.;

1.2.блоклы торак төзелеше өчен - 1 000 кв.м.;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен - 1 000 кв.м.

2. Гражданнарга милек буларак бирелә торган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге милкендәге дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренең иң чик максималь күләмнәрен түбәндәгечә билгеләргә:

2.1. торак пунктлар чикләрендә индивидуаль торак төзелеше өчен - 2 000 кв.м.;

2.2. блоклы торак төзелеше өчен -2 000 кв.м;

2.3. шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен - 5 000 кв.м.

3. Гражданнарның фактта файдалануында булган яисә әлеге кагыйдәләр үз көченә кергәнче бирелгән җир участогының зурлыгы законда билгеләнгән тәртиптә бирелгән иң чик минималь зурлыктан кимрәк булса, йә әлеге җир участогы өчен аның зурлыгы максималь чик күләмнән артып киткән очракларда, әлеге җир участогы өчен аның зурлыгы минималь яисә максималь чик зурлыклар булып тора.

4. Гражданнарның даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану яисә гомерлек мирас итеп биләү хокукындагы җир кишәрлекләренә карата җир кишәрлекләренең иң чик зурлыгы кулланылмый.

5. Бирелә торган җир кишәрлекләренең мәйданы әлеге статьяның 3 пункты нигезендә төгәлләштерелгәндә, аерма кимендә 10 % тәшкил итәргә мөмкин.

6. Иң чик күләмнәргә карата, нормадан артып киткән кишәрлекнең бер өлеше мөстәкыйль җир участогы буларак формалаштырыла алмаса һәм кызыксынган җирләрдән файдаланучылар килештерелгән очракта, иң чик күләмнәрдән артып киткән җир кишәрлекләре искәрмә булып тора».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе — А. Ә. Шәфигуллин